Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.01.2025_ Менделеевск ш. № 44

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль
районы территориясендә муниципаль маршрутларда
автомобиль транспортында җайга салынмый
торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар
йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле
эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкаруга чыгымнар
өлешен каплау максатларында ташучыларга субсидияләр
бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 16 ноябрендәге 1573 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2024 елның 17 маендагы 287 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлард автомобиль транспортында җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында ташучыларга субсидияләр бирү тәртибенең 8 бүлегендәге 8.1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәгечә бәян итәргә:

«8.1. сайлап алуны уздыру турында белдерүне бердәм порталда яисә башка сайтта урнаштыру датасын (Сайт битенең күрсәткечен бердәм порталда урнаштырып) (бюджетында федераль бюджеттан бюджетара трансфертларның исәп-хисап өлеше (субвенцияләрдән тыш) соңгы өч хисап финанс елының икесе дәвамында үз керемнәре күләменең 20 процентыннан артмаган Россия Федерациясе субъектының югары башкарма органы билгеләгән очракта) Россия Федерациясе субъектының берләштерелгән бюджеты, күрсәтелгән Россия Федерациясе субъектының югары башкарма органы, күрсәтелгән Россия Федерациясе субъекты территориясендәге муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78_5 статьясындагы 7 пунктының икенче абзацы нигезендә сайлап алуны һәм карар кабул итүне уздыру максатларында Россия Федерациясе субъектының дәүләт мәгълүмат системалары), шулай ук кирәк

булганда "Интернет"челтәрендә бюджет акчаларын баш бүлүченең рәсми сайтында;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында (www.mendeleevsk.tatarstan.ru ) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.Ф. Исхаков